ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЧКЕТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЧКЕТАҢ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.12.2023 Кичкетаң авылы № 16

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитетының 08.12.2017 елның 10 номерлы «Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус бүлеп бирелгән урыннар һәм биналар исемлеге һәм биналар бирү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитетының 08.12.2017 елның 10 номерлы «Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус бүлеп бирелгән урыннар һәм биналар исемлеге һәм биналар бирү тәртибе турында»карарына кушымтадагы үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының рәсми сайтында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе И.Н. Җиһангәрәев

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитетының
2023 елның 21 декабрьдәге 16 номерлы
карары белән расланды

## Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитетының 08.12.2017 елның 10 номерлы «Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус бүлеп бирелгән урыннар һәм биналар исемлеге һәм биналар бирү тәртибе турында» карарына кертелә торган үзгәрешләр

1. Карар преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе сенаторы статусы һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты статусы турында» 1994 елның 8 маендагы 3-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге җыелышлары, митинглары, демонстрацияләре, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә: »;

2. 3 нче кушымтаның 1 пунктында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты статусы турында» 1994 елның 8 маендагы 3-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә» сүзләрен «Россия Федерациясе сенаторы статусы һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты статусы турында» 1994 елның 8 маендагы 3-ФЗ номерлы, 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга,»;

3. 3 нче кушымтаның 5 пунктындагы 3 абзацында «Россия Федерациясе субъекты» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

4. 3 кушымтаның 5 пунктындагы 3 абзацында 3 һәм 4 җөмләне төшереп калдырырга;

5. 3 нче кушымтаның 6 пунктындагы 6 пунктчасында «медицина ярдәме» сүзләреннән соң «һәм санитария хезмәте күрсәтү» сүзләрен өстәргә;

6. 3 бүлекнең 3 пунктында «Карарның 2 пункты нигезендә» сүзләрен «Карары» сүзләренә алмаштырырга;

7. 3 бүлекнең 6 пунктының 13 абзацында, 9-11 пунктларында «оешма җитәкчесенә», «оешма җитәкчесе», «оешма җитәкчесе белән», «учреждение җитәкчесе» сүзләрен тиешенчә «башкарма комитет җитәкчесенә», «Башкарма комитет җитәкчесе», «Башкарма комитет җитәкчесе белән», «Башкарма комитет җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга.